**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 14 декабрь № 943

г. Казань

Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча еллык республика экспертлар конкурсы турында

Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча иң актив экспертларны бүләкләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Ел саен норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча республика экспертлар конкурсын уздырырга.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча еллык республика экспертлар конкурсы турындагы нигезләмәне;

норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча еллык республика экспертлар конкурсын уздыру буенча комиссия составын.

3. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча еллык республика экспертлар конкурсын финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын гамәлгә ашыруга күздә тотылган акча чикләрендә тормышка ашырыла, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт

программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карар проектын билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча еллык республика экспертлар конкурсын уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\943.doc